26. Mansurov, Z. (1998). *Yashəү үzəne* [The Valley of Life]. 319 p. Kazan, Tatar.kit.nəshr. (In Tatar)

27. Mirza, M. (2018). *Sailanma əsərlər: bish tomda* [Selected Works: In Five Volumes]. T. 1, 334 p. Kazan, Məgarif – Vakyt nəshr. (In Tatar)

28. Mirza, M. (2018). *Sailanma əsərlər: bish tomda* [Selected Works: In Five Volumes]. T. 3, 357 p. Kazan, Məgarif – Vakyt nəshr. (In Tatar)

29. Kharis, R. (2021). *Min – mil'on yash'lek keshe!* [I Am a Million Years Old!]. Kazan utlary. No. 5, pp. 3–9. (In Tatar)

30. Shərifullina, E. (2022). *Sugysh kyrlarynnan min kaitsam?..* [If I come back from the battlefield alive?..]. Kazan utlary. No. 6, pp. 102–104. (In Tatar)

---

# ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ СУГЫШ МОТИВЫ (БӨЕК ВАТАН СУГЫШЫНА БАГЫШЛАНГАН ӘСӘРЛӘР МИСАЛЫНДА)

**Нурфия Марс кызы Юсупова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 йорт,
faikovich@mail.ru

Мәкалә Бөек Ватан сугышы чорыннан башлап, бүгенге көнгә кадәр татар шигъриятендә сугыш мотивының чагылышын, үсеш-үзгәрешен өйрәнүгә йөз тота.

XX йөз татар шигъриятендә сугыш мотивының активлашуы узган гасыр башына карый. Инкыйлаб, гражданнар сугышы елларында көчәеп алса да, аның, системалы рәвештә бербөтен булып, үсеш-үзгәрештә яктыртылышы Бөек Ватан сугышына багышлап язылган әсәрләргә барып тоташа. Шуңа да мәкалә чикләрендә XX гасыр татар шигърияте тарихында сугыш мотивының үсеш үзенчәлеген һәм трансформациясен күзәтү Бөек Ватан сугышы чорында язылган әсәрләрдән башлана һәм XXI гасыр башы шигъриятенә кадәр дәвам итә. Бөек Ватан сугышы иҗтимагый тормышка гына түгел, сүз сәнгатенә дә зур йогынты ясый, аның үсешендәге зур идея-эстетик үзгәрешләргә сәбәп була. XX гасырның буеннан-буена яктыртылган әлеге мотив шигъриятнең үсеш юлын, андагы үзгәреш-борылышларны, идея яңарышын ачык күрергә мөмкинлек бирә.

Әлеге мәкаләнең төп максаты – Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәтле язылган әсәрләргә таянып, XX гасыр татар поэзиясендә сугыш мотивының чагылышын, үсеш-үзгәрешен өйрәнү. Максатка ярашлы төстә төп өйрәнү объектын 1941 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәр язылган шигъри әсәрләр тәшкил итә.

Бер яктан, милли шигъриятьтә әлеге мотивның үсеш-үзгәрешен системалы өйрәнгән һәм заманча теоретик база нигезендә тикшергән хезмәтләрнең булмавы, икенче яктан, Җиңүнең 80 еллыгын билгеләп үткән дәвердә бу юнәлештәге шигъри әсәрләргә яңача бәя бирү зарурлыгы хезмәтнең актуальлеген билгели.

**Төп төшенчәләр:** татар шигърияте, Бөек Ватан сугышы, мотив, трансформация, тема, лирик герой

**Сылтама өчен:** Юсупова Н. М. Татар шигъриятендә сугыш мотивы (Бөек Ватан сугышына багышланган әсәрләр мисалында) // Tatarica. 2025. № 2 (25). 46–65 б. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-46-65

## Кереш

Мотив төшенчәсе әдәбият белемендә иң эшкәртелгән, өйрәнелгән өлкәләрдән санала. Әдәби төшенчә буларак, мотив XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында А.Н. Веселовский (1838–1906) хезмәтләреннән юл ала. Үзенең «Типология сюжетов и мотивов» хезмәтендә галим мотивны текстның аерылгысыз элементы буларак тәкъдим итә; халык авыз иҗаты әсәрләр мисалында аны сюжетның кечкенә бер өлеше төсендә билгели. Галим мотивның төп билгесе буларак, константа һәм үзгәреп торучы кисәкләрне тоташтырудан хасил булган образлы схематизмны күрсәтә. Мотивның мондый аңлатылыш варианты Б.Н. Томашевский хезмәтләрендә дә урын ала. Ул мотивны әдәби әсәрнең таркалмый торган өлеше дип билгели һәм әдәбият белемендә мотивны сюжетның хәрәкәттәге иң кечкенә берәмлеге итеп карау киң таралыш ала [1, б. 594]. Мәсәлән, әсәрләрдә мәхәббәткә омтылу, мәхәббәт өчпочмагы, герой белән тирәлекнең аңлашмаучылыгы, яхшылык һәм явызлык көрәше, бәхетле булырга теләү, тормыш мәгънәсен эзләү кебек мотивлар төрле элементларда: сюжет, геройлар бирелешендә, аерым вакыйгаларда, конфликтларда һ.б. очрый. Шигърияттә ачкыч-сүзләр мотив вазифасын башкара. Мотив бер яки берничә әсәрдәге предметта күрсәтелә ала [2, б. 230].

Галимнәр тарафыннан мотивның гомумтанылган бер билгесе буларак, аның кабатлануы билгеләнә. Язучы иҗатында яки әдәбиятта кабатлану аша мотивлар лейтмотив төсен ала. Әдәби әсәрдә лейтмотив та, мотив та текстның икенчел эчтәлеген, яшерен мәгънәсен тудыруда әһәмиятле роль уйный. Дөнья әдәбиятында кабатланган, төрле әдәбиятларда күчеп йөри торган мотивлар белән янәшәдә аерым бер әдәбиятлар яки аерым бер чор сүз сәнгате өчен генә хас мотивлар да яшәп килә. Сугыш мотивы шундыйлардан. Бөек Ватан сугышында җиңүгә 80 ел тулса да, әлеге мотив татар әдәбияты өчен әһәмиятен югалтмый, еллар аша әдипләр аңа яңа яссылыкта якын килә, заман күзлегеннән чыгып сурәтли.

Татар әдәбиятында Бөек Ватан сугышының чагылышы Д.Ф. Заһидуллина [3], Н.М. Юсупова [4; 5], Г.Р. Гайнуллина [5; 6], Ф.И. Габидуллина [7], В.Ф. Макарова һәм Г.Ф. Каюмова [8] һ.б. галимнәрнең мәкаләләрендә өйрәнү объекты итеп күтәрелә. Моннан тыш, А.Ю. Хәбетдинов һәм М.М. Хәбетдинова [9], Л.Р. Нәсыйхова [10; 11] үзләренең хезмәтләрендә сугышның публицистик материалда чагылышын өйрәнүне максат итеп куя.

## Хезмәтнең методологик нигезе

Хезмәтнең методологик нигезен герменевтик эзләнүләр [12], ә методик нигезен Б.Л. Борухов тәкъдим иткән «мотивлаштырылган поэтика» тәшкил итә [13]. Тикшеренү барышында мотивацияләүнең Б.Л.Борухов хезмәтләрендә билгеләнгән мәдәни, конвенциаль, менталь төрләреннән конвенциаль тибы максатка ярашлы дип табылды. Бу тип мотивацияләү әдәби текстлар һәр чорда үз кануннарына буйсынып яки аларны кире кагып мәйданга чыга дип белдерә. Конвенциаль мотивацияләү XX гасыр татар поэзиясендә сугыш мотивының үсеш-үзгәреш юлларын, трансформация үзенчәлеген билгеләргә мөмкинлек бирә. Мәкаләне язу барышында шулай ук тасвирлама һәм аксиологик методлар да файдаланылды.

## Фикер алышу

Бөек Ватан сугышы чоры шигъриятендә сугыш мотивы иң актив, һәр шагыйрь иҗатында урын алган лейтмотив буларак мәйдан яулый һәм төрле поэтик жанрларны колачлап ала. Аның активлашуы татар поэзиясендә әлеге мотивка бәйле темаларның тармаклануына китерә: халыкны көрәшкә чакыру (Ә. Ерикәй «Сугышка, иптәшләр» (1941), җиңүгә ышаныч, илне сакларга ант бирү (Ф. Кәрим «Ант», 1942; М.Җәлил «Тупчы анты», 1941; М. Хөсәен «Туган ил өчен», 1941), дошманга нәфрәт (К. Нәҗми «Фашизмга – үлем!», 1941; Ш. Мөдәррис «Башланды», 1941; Ә. Исхак «Канга – кан», 1941), туган җир белән саубуллашу, солдатны сугышка озату белән бәйле сагыш, хушлашу тудырган фаҗига (Ш. Маннур «Саубуллашу җыры», 1942; Г. Кутуй «Озату җыры», 1942; К. Нәҗми «Озату», 1942; Ф. Кәрим «Соңгы тапкыр карыйм Иделгә», 1942), батырлык, җиңүгә ышаныч (Ш. Мөдәррис «Землянкада», 1943; С. Хәким «Хат», 1942; Ә. Фәйзи «Фронт юлында», 1943; Ш. Мөдәррис «Сапер», 1943), тылдагы хатын-кызларның хезмәт батырлыгы («К. Нәҗми «Хәят апа», 1941; «Сагыну хаты», 1942) темалары яктыртыла. Максатка ярашлы төстә сугыш мотивына язылган әсәрләр агитатор һәм пропагандист вазифаларын үти башлый, «Ватан өчен!», «Җиңү өчен!» лозунглары әдәбиятны иңләп ала, шуңа да сугышның баштагы чорында поэтик әсәрләр нигездә публицистик

характерда булып, халыкны дошманга каршы бердәм көрәшкә күтәрелергә чакырып языла.

Сугыш мотивы шигърияттә яшәү һәм үлем фәлсәфәсенең яңарышына китерә. Шушы дулкында шигъри әсәрләр структурасы яшәү / үлем, без / дошман (М. Җәлил «Окоптан хат», 1941; «Тупчы анты», 1941 һ.б.), туган җир / чит җир (Ф. Кәрим «Шомырт куагы» 1942; «Бездә яздыр», 1942; М. Җәлил «Алман илендә», 1943 һ.б.), сугыш / тынычлык (Ә. Ерикәй «Караңгыда гына сугыш тынды», 1942; М. Җәлил «Чулпанга» (1941) һ.б.) бинар оппозицияләренә корыла башлый. Әдәбият алдына куелган максатлар яшәү-үлем фәлсәфәсенең яшәү – үлем – үлемсезлек формуласы аша чагылышына алып килә һәм яшәү ил өчен көрәш, Ватан өчен үлем ил халкы күңелендә мәңге яшәү белән тәңгәлләштерелә (М. Җәлил «Әйдә, җырым», 1941; «Чулпанга», 1941; «Хуш, акыллым, 1941; Ф. Кәрим «Ватаным өчен», 1942; «Сөйләр сүзләр бик күп алар...», 1942 һ.б.): *Үлем турында уйлама, / Илең турында уйла, / Илең турында уйласаң, / Гомерең озын була* [14, б. 170].

Бу чор татар шигъриятендә сугыш мотивының көчәюе лирик герой концепциясен дә үзгәртә: лирик герой ил азатлыгы өчен көрәшкә чыккан, ахыргы канынача илен сакларга әзер кыю солдат буларак мәйдан яулый. Совет мифының иң динамик, үзгәрүчән образы – герой архетипик образы агымдагы чор татар поэзиясендә герой-сугышчы утлар-сулар кичеп чыккан Ватан солдаты, ил язмышы өчен соңгы тамчы канын да кызганмаган, «*Үзең турында уйлама, илең турында уйла*» дип фикер йөрткән каһарман булып мәйданга чыга. Мондый тип лирик герой Ш. Мөдәрриснең «Таныш куак» (1942), «Землянкада», «Сукыр лампа» (1943), С. Хәкимнең «Хат» (1942), «Дуслар», «Иртән», «Урман» (1943), Ә. Исхакның «Ал гитараңны, сеңел» (1943), Ш. Маннурның «Ял минутларында», «Йөрәк типкән саен дәшәм аңа», «Солдат моңнары» (1943), Ә. Ерикәйнең «Утыр, дускай, әзрәк серләшербез» (1943), «Кышкы кичтә» (1944), Б. Рәхмәтнең «Сәлам хаты» (1943), Ә. Фәйзинең «Вагонда», «Фронт юлында» (1943) һ.б. шигырьләрдә ачык чагыла. Моннан тыш, ул төрле модификацияләрдә – герой-сугышчы, герой-корбан буларак та тәкъдим ителә башлый. Шушы дулкында шигъри әсәрләрдә көрәшче – сугышка керүче, дошман – Гитлер, фашист, талаучы кебек сурәтләр тотрыклы төс ала [15, б.194]. Мисал өчен, Ә. Фәйзинең «Кисеп ташла фашист тилчәсен» (1941) шигырендә шундый натуралистик образ авторның дошманга мөнәсәбәтен ачуга юнәлтелә: *Күрән агу ялгыш, кара аны, / Йөрәгенә җирнең үтмәсен, / Син аяусыз кулың белән тизрәк / Кисеп ташла фашист тилчәсен!* [16, б. 47]. Мондый үзенчәлек М. Җәлилнең «Әйдә, җырым» (1941), «Дошманга каршы» (1941), «Соңгы көрәшкә» (1941), «Тупчы анты» (1941), Ф. Кәримнең «Ант» (1942), «Ватаным өчен» (1942), «Дингез ярында» (1942), «Исә җил» (1942), «Хәнҗәр» (1943), Н. Баянның «Өч бөркет» (1942), С. Хәкимнең «Хат» (1942), «Кошлар» (1942), «Фронтовик» (1942) һ.б. шигырьләрдә дә күзәтелә.

Сугыш мотивы татар шигъриятенең поэтик яссылыкта үзгәрешенә, төрләнәнүенә дә тәэсир ясый. Аны сурәтләү юлында шагыйрьләр җыр, туган җир, яз, ләйсән яңгыр, кояш, нур, чәчәк, гөл, күз, алмагач кебек фольклор образларына иркен мөрәҗәгать итә башлый, шушы яссылыкта татар поэзиясе утызынчы елларның икенче яртысында халык авыз иҗаты образларына мөрәҗәгать аша башлаган тенденцияне үстереп, камилләштереп китә. Романтик буяуларда сурәтләнгән солдат халык авыз иҗатының әкият-дастаннарындагы сурәтләр, шартлы алымнар һәм тел чаралары ярдәмендә ачыла. Мәсәлән, Ш. Маннурның «Кыр казлары» (1943), «Җиңү балдагы» (1944) шигырьләрендә урын алган «күкрәген җилгә куеп баручы» сугышчы образы шундыйлардан. Бу күренеш сугышны сурәтләү юлында милли шигъриятнең социалистик реализм белән генә чикләнмәве, эзләнүләр юлында классик нигезләргә борылышы турында сөйли. Ә. Фәйзинең «Йолдыз» (1942), «Бүләк» (1942), «Бу яз» (1943), «Каштан чәчәк ата» (1944), Г. Хуҗиның «Днепр дулкыннары», «Сентябрь», «Учак янында», «Ул һәркайда», Н. Арслановның «Авылда», Ә. Юнысның «Язгы тойгы», «Идел кыясы», «Солдат йөрәге», Ә. Исхакның «Күз», «Котырынсын буран», С. Хәкимнең «Үзәнлектә җилләр уйнап йөри» (1943), «Урман» (1943-1944), Ш. Маннурның «Чәчәкләр һәм снарядлар» (1943) кебек шигырьләрендә дә фольклор элементлары сугышчы-солдатның батыр көрәшен гәүдәләндерүдә, сугыш кырларындагы солдатның эчке дөньясын ачуда файдаланыла. Ш. Маннурның «Туплар гөрли», «Без киләбез күкрәп», «Синең бөек исемең белән» (1943), «Кояш баешына» (1944), «Җиңү балдагы», «Уйлар» (1945), Ш. Мөдәрриснең

«Севастополь», «Смоленщина», «Тантана», «Кинҗәбулат», «Сапер», «Киткәндә» (1943), «Бөек дуслык», «Белоруссия» (1944), Б. Рәхмәтнең «Синең хакың бар» (1943), «Безне көтәләр» (1944), Ә. Ерикәйнең «Ач капкаңны, Кырым» (1943), «Күтәрик бокалларны» (1944), «...Өч көн инде, өч төн туктамыйча» (1944), Ә. Фәйзинең «Бу яз» (1943), «Каштан чәчәк ата» (1944), С. Хәкимнең «Куллар» (1942), «Хат» (1942), «Гарәфи дус» (1944), «Колын» (1944), «Һөҗүм алдыннан» (1945) кебек шигырьләрендә халык авыз иҗатыннан билгеле, традицион образлар җиңүгә юл ярып баручы солдатның шатлыгын җиткерүгә юнәлтелә.

Романтик эчтәлекле фольклор образларына мөрәҗәгать итү тенденциясе 1942 елдан соң язылган лирик һәм лиро-эпик әсәрләрдә аеруча активлашып китә. Фольклордан үстерелә килгән табигать сурәте лирик герой хисләренең сәнгати рәсемен тудыру өчен дә, фәлсәфи фикерләрне һәм автор позициясен җиткерүче символик яки аллегорик образлар статусында да, сугыш мотивының гәүдәләнеше буларак та кулланыла. Мәсәлән, Ф. Кәримнең «Бездә яздыр» (1942) шигыре сугыш мотивы сугыш / тынычлык оппозициясе аркылы ачыла. Шагыйрь ике дөньяны – фашистлар кулындагы һәм илнең тыныч җирләрен каршы куеп сурәтли. Хат-монолог формасында иҗат ителгән шигырьдә яз образы өмет, яңару, якты киләчәк символына әверелә һәм авторның сугышка мөнәсәбәтен җиткерә: *Яшен уты белән күккә язып әйтәм / Язы юкның яшәү хакы юк!* [17, б. 63]. Шигырь тукымасында үз-үзе белән каршылыкка кергән яз образы аша Ф. Кәрим гомумиләштерелгән фикерен җиткерә: әлеге сугыш кешелекне генә түгел, табигатьнең матурлыгын, асылын да юкка чыгара. Яисә «Сибәли дә сибәли» (1942) шигырендә көзге яңгыр образы сугыш кырларында якын иптәшен югалту хәсрәтеннән газапланучы лирик герой кичерешләрен ачарга ярдәм итә. Көзгеле композициягә корылган шигырь тукымасында сибәли дә сибәли рефренының кабатлануы, сынландыру алымы, трагик пафос, кабатлау композицион алымы, үзенчәлекле метафора-эпитетлар – барысы да сугышчы-лирик геройның хис-кичереш дәрәҗәсен көчәйтү, сугыш фаҗигасен тирәнәйтү чарасына әверелә: *Япь-яшь иптәшне күмәбез, / Беркем берни сөйләми, / Көзге төндә яңгыр гына / Сибәли дә сибәли* [17, б. 67].

С. Хәкимнең «Колын» (1944) шигырендә колын язмышы укучыда төрле уй-тойгылар уятуга юнәлтелә: ул сугышның фаҗигасен аңлатырга да мөмкинлек бирә, сугыш китергән хәсрәтләрнең бер генә тере җан иясен дә читләтеп үтмәвен дә ассызыклый, әтисез калган балалар фаҗигасе булып та укыла: *Тәртәгә ауган атның ул / Сыртыннан тешләп куя. / Кем белән хәзер шаярсын? / Юксынып кешнәп куя* [18, б. 61].

Тематик-поэтик үзгәрешләр белән бергә, сугыш мотивы юмористик-сатирик материалда да яктыртыла башлый. Мәсәлән, Ә. Фәйзинең «Бүре походы» (1942), «Гитлер һәм Герострат» (1942), «Төш күрүче фашист генералы турында» (1944) кебек сатирик шигырьләрендә сугыш мотивы сарказм, ирония, аллегорик образлылык, гипербола, киная алымнары ярдәмендә тирәнәйтелә. Әдипнең «Әүхәдинең хатыны Майшәкәр белән саубуллашуы» (1944) әсәрендә кеше холкындагы кимчелекле күренешләрдән көлү сыйфаты сугыш вакыйгаларына мөнәсәбәтле ачыла. Автор Майшәкәрнең ирен сугышка озатучы әзерләү вакыйгасын көлү чыганагына әйләндерә, аны гипербола алымы аша көчәйтә һәм Әүхәди һәм Майшәкәр мисалында сугышта һәркемнең үз хакыйкате дип кабатлый.

Сугыш чоры поэзиясендә сугыш образының икенчел эчтәлек тудыруда, эзоп теле алымы буларак катнашып китүе милли шигърияткә хас бер үзенчәлек булып оешып җитә. Бу күренеш Х. Туфан иҗатында тотрыклы төс алып, аның сугыштан соңгы еллар иҗатында да дәвам итә, сугыш лирик геройга эчке эчтәлек аша тоткынлык газапларын җиткерергә мөмкинлек бирә. «Гөлләр инде яфрак яралар» (1945), «Каеннар сары иде» (1942), «Чәчәк сибелә җилдә» (1947), «Тынма, давыл» (1951), «Моабитны күрдем төшемдә» (1947), «Сугыш» (1947) кебек шигырьләр шул хакта сөйли. Мондый шигырьләрдә үзәк фикер сугыш образы ярдәмендә ачыла һәм Туфанның үз язмышын чагылдыру яки ярдәмче мотив буларак урын алган шул чордагы ил халәтенә бәя бирү чарасына әверелә. Мәсәлән, «Чәчәк сибелә җилдә» (1947) шигырендә ике кулын артка куеп, кешене атарга алып бару сурәте аша сугыш, тоткынлык фаҗигасе җиткерелә. Кешене табигатьнең, кешелекнең бер кисәге итеп карап, Туфан бу фаҗигагә киләчәк гасырлар күзлегеннән, гуманизм, гомумкешелек фәлсәфәсе ноктасыннан бәя бирә. Яисә «Илдә ниләр бар икән?» (1944) шигырендә илдә барган сугыш икенчел эчтәлектә пожар образы аркылы ачыла һәм ил,

халык фаҗигасе төсендә бәяләнә: *Илдәниләр бар икән: / Юллар зәңгәр кар микән? / Һавадагы алсу шәүлә / Пожар микән, таң микән? / Илдәниләр бар микән?* [19, б. 233].

Чор шигъриятендә сугыш мотивын лиро-эпик әсәр тукымасында яктырту омтылышы поэма (Ф. Кәрим «Партизан хатыны», 1943, «Гөлсем», 1942, «Идел егете», «Үлем уены», 1942; К. Нәҗми «Снайпер Мәрдән», «Фәридә», 1944; Ш. Мөдәррис «Тупчы Ваһап», 1943) жанрының активлашуына китерә. Аның ике төре – эпик (Ф. Кәрим «Гөлсем», 1941-42, «Үлем уены», 1942; Н. Арсланов «Мәхәббәт», С. Баттал «Берлинга һөҗүм», Ш. Мөдәррис «Тупчы Ваһап», Г. Хуҗи «Яу күрке» һ.б.) һәм лирик поэмалар (Ф. Кәрим «Кыңгыраулы яшел гармун», 1942, «Идел егете», 1942; С. Баттал «Тын диңгез ярларында», Ә. Маликов «Атаудагы хисләр» һ.б.) иҗат ителә. Сугыштагы солдат кичерешләрен, аның илен, якыннарын сагыну, юксыну тойгыларын җиткерү теләге нәсер жанрының яңаруына да тәэсир итә. Г. Кутуйның «Без – сталинградчылар» (1943), «Сагыну» (1945) нәсерләре шул хакта сөйли.

Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануы, җиңү шатлыгы 1950 еллар поэзиясендә сугыш мотивының эчтәлегенә дә йогынты ясый. Героик-романтик пафос көчле булган әсәрләр шигъри мәйданда үзгә сукмаклар сала башлый һәм «социалистик миф» кысаларыннан чыгып китә. Мондый шигырьләрдә җиңү романтикасы, җиңү эйфориясе хис-кичереш дулкынын тәшкил итә, шуның яктылыгында Ә. Фәйзинең «Яратам мин сине, туган илем» (1952), Ш. Маннурның «Дуслар рухына», «Ак лачын», «Тыныч яз», С. Урайскийның «Сугыш бетте», Н. Дәүлинең «Өч тамчы су турында баллада», М. Садриның «Тормышка ода», М. Хөсәеннең «Ак чәчәкләр», Г. Латыйпның «Сугышларның яңа беткән чагы» һ.б. шигырьләрендә җиңүче солдатны данлаган, олылаган, җиңүгә өлеш кертүе белән горурланучы, тыныч тормышка гашыйк лирик герой мәйданга чыга. Ә. Фәйзинең «Сайладым» (1947), «Халкыбыз» (1950), «Бер йөрәктән бөтен телләрдә» (1951), «Яратам мин сине, туган илем» (1952) кебек шигырьләрендә бердәм ил, халык теләсә нинди авырлыкларны җиңеп чыга ала дигән фикер үткәрелә. Көрәшче-егет образын тудыручы детальләр төсендә лачын, ак нур, көмеш саплы кылыч, зәңгәр билбау кебек таныла торган берәмлекләр көрәшче образының милли аңланылышын көчәйтә. Әнә шулай сугыш чоры татар шигъриятендә башланып киткән сыйфат үзгәрешләре бу чорда дәвам итә, үстерелә.

Әлеге тенденция туган ил, туган җир образының бирелешендә дә күренә. Сугыш мотивына корылган шигъри әсәрләрдә туган ил, туган җир образының мәгънәви аңланышы киңәя. Сугыш чорында язылган шигырьләрдән аермалы буларак, ул якланырга, сакланырга тиеш үзәктән, яклап кан түгелгән, җырлар җырланырга, гөлләр үсәргә тиешле җир төсен ала һәм Ә. Фәйзинең «Яратам мин сине, туган илем» (1952), С. Хәкимнең «Башка берни дә кирәкми» (1959), «Иделкәем минем»(1953), Ә. Ерикәйнең «Җәйнең аяз таңнарында», М. Ногманның «Каеннар шаулый» һ.б. шигырьләрдә аерым бер җылылык белән сурәтләнә башлый. Аны сурәтләү барышында идеологик эчтәлекле образларга түгел, халык авыз иҗаты образларына, романтик сурәтлелеккә актив мөрәҗәгать ителә. Шуның белән янәшәдә Ш. Маннурның «Ак лачын», Ә. Давыдовның «Ана кабере» һ.б. шигырьләрдә Ватанны мифлаштыру күренеше, туган ил – туган җир – Ватан-Ана чылбыры көчәя.

Икенче яктан, сугыш мотивына корылган шигырьләрдә кайтмый калганнарны юксыну аша сугыш афәтен бәяләргә омтылу (Ә. Фәйзи «Ач тәрәзәң», 1945; С. Хәким «Көткән идем, 1946; Ш. Галиев «Үткәйгә хат», 1947) алгы планга чыга. Мондый әсәрләрдә сугыш темасының сурәтләнеше үзгәреш кичереп, әлеге үзгәреш лирик герой концепциясендәге яңарыш белән янәшәлектә бара. Әдәби мәйданга сугыш фаҗигасен буыннар фаҗигасе итеп таныган, җимерелгән язмышлар өчен әрнүче лирик герой килә, аның модификацияләренең берсе буларак, үткәндәге сугыш вакыйгаларыннан газапланучы герой алга чыга, шуның тәэсирендә шигърияттә психологизмның көчәюе күзгә ташлана [4, б. 84]. Илнең эчке фаҗигасе белән күзгә-күз очрашканнар яисә шәхес культы нәтиҗәләрен аңлый-күрә алучылар иҗатында бу гамь ил, милләт киләчәге өчен кайгыруга әверелә. Шушы чордан татар шигъриятендә сугыш мотивын лирик-психологик һәм фәлсәфи яссылыкта ачу тенденциясе урнаша һәм XX гасырның икенче яртысында бу үзенчәлек татар шигъриятенә хас гомумсыйфат булып формалашып җитә.

Мондый эчтәлектәге шигырьләрдә «яралы йөрәк», «таланган ил», «таланган җан» сурәте калка [20, б. 411]. Мәсәлән, С. Урайскийның

«Син кайтмадың», «Сугыш бетте», С. Хәкимнең «Сары капкалы йорт» (1958), Ә. Фәйзинең «Сайладым» (1947), Ә. Ерикәйнең «Төннәр буе йоклый алмый ятам» (1948), Х. Туфанның «Чәчәк сибелә җилдә» (1947), «Киек казлар» (1953) , «Сабыр буламы соң сагыш» (1953) һ.б. шигырьләрдәге сагыш, кайгы хисләре, моитвлары иҗтимагый сәбәпләргә яки шуларга бәйле шәхес фаҗигасенә тоташа. Сугышчы-солдат язмышы – ил язмышы чылбыры иҗатчылар тарафыннан яңа яссылыкта аңлана башлый. Җимерелгән язмышлар ил киләчәгенә бәйле күзаллана: һәр кеше бәхете – ил бәхете, һәр кеше кайгысы ил кайгысы дәрәҗәсенә күтәрелә (Ә. Фәйзи «Кырык яшь», 1948; «Сайладым», 1947 һ.б.).

Сугыштагы батырлык һәм фаҗигаләр турында лирик уйланулар С. Хәкимнең «Курск дугасы» (1948) поэмасында да шактый тулы чагыла. Лирик герой үзе сугышкан җирләр аша уза, шул чор хәлләрен һәм кешеләрен күңеленнән кичерә. Таныш урыннарга бәйле вакыйгаларны сурәтләүдән бигрәк, шулардан алынган тәэсирләр, хисләр алга чыга. Шулай да лирик герой кичерешләре күбесенчә искә төшерү, бүгенгене күреп шатлануга кайтып кала һәм аларның җирлеге дә тар: колхоз басулары, авыл, өйләр... Соңрак иҗат ителгән «Дуга» (1968) поэмасында зур тарихи вакыйгаларга бәйле уйланулар, күп авырлыклар күргән кешеләрнең хис-тойгылары тагын да калкурак сурәтләнә. Романтик табигатьле «Дала җыры» (1948–1975) һәм «Бакчачылар» (1952–1965) әсәрләре кеше рухын, батырлыгын вакыйгалы фонда һәм мөмкин кадәр психологик тирәнлектә ачарга тырышу белән аерылып торалар.

XX гасырның икенче яртысыннан татар шигъриятендә башланган үзгәрешләр, поэзиянең эчтәлек һәм форма ягыннан яңарышы [21, 4 б.] Бөек Ватан сугышына мөнәсәбәтле язылган әсәрләргә дә йогынты ясый. Бу чорда иҗат ителгән әсәрләрдә сугыш, героик-романтик пафосны белдерүдән бигрәк, яшәешкә мөнәсәбәтле фәлсәфи уй-кичерешләрне җиткерүгә йөз тота. Иҗтимагый үзгәрешләр сугышка фаҗигале үткән итеп карау тенденциясенең активлашуына сәбәп була. Мәсәлән, С. Хәкимнең «Бер бәйгедә күргән идем аны...» (1962), «Әле һаман куркып уянамын» (1961), «Немец дәфтәреннән» шигырьләр бәйләмендә (1978–1982), «Сугышның дәһшәте, көче» (1979), «Дуга» (1968), Х. Туфанның «Сугыш килә Мисыр өстенә» (1956), «Без уникәү идек...» (1960), Ш. Галиевның «Әткәй» (1957), Роб. Әхмәтҗановның «Соңгы танк» (1963), Ә. Баяновның «Сталинград» (1967), Х. Әюповның «Атлар» (1970), А. Хәлимнең «Туган җиремә» (1967) һ.б. шигырь-поэмалары шул хакта сөйли. Н.Л. Лейдерман, рус шигърияте мисалында, мондый шигырьләрдә «рухи өлгергән лирик геройның алга чыгуын һәм шигырь структурасында тарихи-фәлсәфи гомумиләштерүләргә омтылышның көчәюен» [22, б. 46-47] билгели. Татар шигъриятендә дә әдәби мәйданга сугыш фаҗигасен буыннар фаҗигасе итеп таныган, җимерелгән язмышлар өчен әрнүче лирик герой килә, аның модификацияләренең берсе буларак үткәндәге сугыш вакыйгаларыннан газаплanучы герой алга чыга, шуның тәэсирендә поэтик әсәрләрдә психологизмның көчәюе күзгә ташлана. Сугыш фаҗигасе белән күзгә-күз очрашкан шагыйрьләр иҗатында бу гамь ил, милләт киләчәге өчен кайгыру буларак үсешен дәвам итә.

Мондый шигырьләрдә сугыш фаҗигале үткән булып төгәлләшә, лирик геройның хисенә сугыш китергән газаплар, аларның күңелдә өзлексез яшәве, ятимлек ачысы, кабат сугыш куркынычы кабыну төп сәбәпләр булып тора, теләсә нинди кан коюны булдырмау теләге шагыйрьләрнең идеалына әйләнә: *Тулы килеш яшьлегемне салдым, / Күпләр салды хәтта башларын... / Нигә мине эзәрлекли сугыш, / Шулмы җитми, шулмы аз тагын? / Хафалана, беләм, борчыла җир, / Ул уята мине, ул дәшеп, / Җан урынында түгел, җир үзе дә / Килә төсле яңа урнашып* [18, б. 179].

«Үткәннәргә хәтта моң кирәк» (1976) дип исемләнгән шигырьләр көлтәсендә дә С. Хәким сугыш сабакларына туктала, кеше язмышы, илнең киләчәге, туачак көннәр аһәңендә поэзиянең роле, иҗтимагый тормыштагы урыны турында уйлануларга күчә. Сугышны туган халкына гына түгел, немец халкына да алып килгән афәт, фаҗига буларак бәяли.

Илдар Юзеевның «Тып-тын иртә» (1960) шигырендә авыл иртәсе тасвирлана, тынлыкны «ярып үткән» протез шыгырдавы укучыны сискәндереп җибәрә: *Йөрәкләргә төшә протез шыгырдавы / Бу кадәре булмый теш сызлавы* [23, б. 31]. Протез тавышы кичәге солдатлар күңелендәге әрнү дә, тарихи хәтернең сугыш фаҗигаләреннән кисәтүе булып та шәрехләнә ала. Әсәрләрен тәэсирлерәк итү максатыннан, үзенең хис-тойгыларын җиткерү юлында татар

шагыйрьләре халык җырларыннан үстерелә килгән тал-тирәк, тополь, гармун, ак каен, җил, шомырт һ.б. романтик образ-детальләрдән файдалануны дәвам итә: *...Җилләр исә, / Җилләр исә, / Каен иелә җилләр искәндә. / Күз яшьләрен яшереп кешеләрдән, / Ана елый, исенә төшкәндә. / Ә ул кайтмый* [24, б. 15].

XX гасырның икенче яртысыннан сугыш мотивына корылган шигырьләрдә батырлык темасы көчле яңгыраш ала һәм еш кына Муса Җәлил яки җәлилчеләр образына бәйле яктыртыла башлый. М. Җәлил һәм җәлилчеләр, гомумән татар кешеләре, каһарманнары образлары ярдәмендә сугыш һәм сугышта күрсәткән батырлык темасына үзгә төсмерләр өстәлә. Шушы фонда рәсми эчтәлекле әлеге темалар идеологик кысалардан чыгып китә. Мисал өчен, С. Хәким «Торыгыз, Мусалар» (1966) шигырендә М. Җәлилне кешелек өчен батырлык үрнәге дип атый, «Татарлар елмаеп үлделәр» (1968) шигырендә М. Җәлил мисалында татарларның батыр халык булуын ассызыклый. Р. Гаташ «Европада татар шагыйрьләре» (1973–1976) шигырендә сугыш кырларында һәлак булып, каберләре Европада калган М. Җәлил, Ф. Кәрим, Н. Баян, Г. Кутуйларның исемен хәтердә яңарта, аларны «Европа өчен гомерләре янган» батырлар итеп сурәтли.

Шушы ук сыйфатлар лиро-эпик әсәрләр өчен дә актуаль булып кала. Мисал өчен, М. Әгъләмовның «Онытма, Европа!» поэмасында җәлилчеләр ил намусы, керсез батырлыгы сагында торучылар дәрәҗәсенә күтәрелә. «Соңгы төн» драматик поэмасында И. Юзеев М. Җәлилнең үлем алды төнен тасвирлый. В. Гетеның «Фауст» әсәре сюжетына аллюзия итеп уйланылган сюжет Яшәү-Үлем каршылыгы бөтенлегендә Муса-Мефистофель бәхәсе төсен ала. Шартлы формада Тиран, Мефистофель, Кыз, Хуҗа һ.б. шартлы геройлар белән сөйләшүләр укучының игътибарын яшәү һәм үлем, яшәү мәгънәсе кебек фәлсәфи мәсьәләләргә юнәлтә. Мефистофель өчен физик юкка чыгуга тиң үлемне Муса үлемсезлеккә бару юлы итеп карый. Ләкин бу әсәрдә, беренче поэмалардан үзгә буларак, азатлык өчен көрәш шәхеснең рухи хөрлеген яклап чыгу дәрәҗәсенә күтәрелә. Рухи көчле кешенең бервакытта да кеше колы булмаячагы һәм кысан кануннарга бирешмәячәге ассызыклана, шагыйрь «бөтен дөньяны төрмә итеп күзаллый» [25, б. 77]. Шушы фонда Шагыйрь җыры («*Җаныма иң соңгы / Җырымны яшердем. / Ул сүнсә – мин сүнәм, / Яшәсә – мин яшим*») кешелекне ирек һәм азатлык өчен көрәшкә өнди, бу сыйфатларны яшәү мәгънәсе дәрәҗәсендә тәкъдим итә. Бу көрәш кешелек дөньясының киләчәге хакына дип гомумиләштерелә. Әгәр Шагыйрь җир шарын үзе белгән гөлбакча хәлендә сакларга омтылса, Тиран аны ут-төтен, машина һәм газап оясы – үзенә хезмәт итүче корган җир итеп күзаллый. Көрәшнең мондый бирелеше иҗат хакындагы идеягә алып килә: шагыйрь – иҗаты белән кешелек язмышы өчен көрәшүче.

И. Юзеевның яшәү һәм үлем фәлсәфәсен әдәби материалда тәкъдим иткән «Тынлык белән сөйләшү» (1966–2000) поэмасында да сугыш мотивы урын ала. Баланың Җир-ана, Гамьсез тынлык, Бер минут тынлык, Атом һ.б. белән сөйләшүенә корылган әсәрдә кешелеккә куркыныч тудырган вакыйгалар искә төшерелә: Икенче бөтендөнья сугышы; Хиросимада атом бомбасы шартлау; атом-төш коралын сынау; совет гаскәрләренең Әфганстанга басып керүе; «Гитлерның варислары» активлашу. Аларның сәбәбе һәм иң олы куркыныч дип, шагыйрь әлеге хәлләргә күз йомуны, гамьсезлекне, битарафлыкны, сугышны атый. Әсәрнең ахырында «Дәшегез, аналар, уянсын балалар!» дигән эндәш кабатлана һәм ул битараф булмаска, гамьсез булмаска чакыру кебек яңгырый.

Шушы чорда сугыш мотивы баллада жанрында активлашып китә. Мәсәлән, И. Юзеевнең «Унике аккош» (1973), Зөлфәтнең «Вәгъдә» (1973), «Марш» (1986), М. Әгъләмовның «Сугышлыда сугыш беткән көн» (1972), «Бердәнбер» (1972), «Төнге баллада» (1976), «Мәңгелек ут» (1977), «Заман язган язмыш» (1987) балладалары шул хакта сөйли. Мондый әсәрләрдә сугышчы образының тиңдәшсез батырлыгына дан җырлана яки бәхетсез мәхәббәт тарихы яңартыла, гомумкешелек мәсьәләләренә йөз тотып, кешелекнең әхлакый яссылыкта фаҗигале үлемгә дучар булуы хакында сөйләнә (Зөлфәтнең «Фатыйма», 1971; «Ике ат турында баллада», 1973; «Кара күбәләк», 1978 балладалары).

Әнә шулай сүз сәнгатендәге милли нигезләргә әйләнеп кайту процессы сугыш, батырлык кебек идеологик эчтәлекле темаларны да халыкчан, милли төсмер белән баета, шуның аша аны рәсми сурәтләнеш чикләреннән алып чыга, сугыш мотивын

сурәтләү юлында башка шигъриятләрдән үзгә «йөзен» таба.

1980 елларның икенче яртысыннан башланган үзгәрешләр татар шигъриятенә, шуның белән янәшәдә сугыш мотивының чагылышына да зур йогынты ясый. Сугышка мөнәсәбәтнең үзгәрүе, үткәндә булган күп кенә вакыйгаларга ревизия ясау XX гасырның икенче яртысы шигъриятендә актив булган сугыш мотивының сүлпәнәюенә китерә. Әмма 2000 еллардан соң сугыш мотивы, элекке еллардагы активлыгын кире кайтара алмаса да, шигърият мәйданында үз урынын кабат яулый башлый.

Бу чорда сугыш мотивы поэма жанрын колачлап ала һәм сугышка бәйле фәлсәфи уйланулар, кеше гомеренең кыйммәте, яшәү мәгънәсе хакында фикерләр белән бәйләнештә ачыла. Шушы юлда авторлар катлаулы символ-метафоралардан, интертекстуаль бәйләнешләрдән, төрле стильләр синтезы, күптавышлылык кебек алымнардан отышлы файдалана. Мәсәлән, З. Мансуровның шагыйрь һәм сугышчы-офицер шәхесенә багышлап иҗат ителгән «Балкыш, яки Хәйретдин Мөҗәйнең сугыш язмаларыннан юллар» (1993–1995) поэма-руладасының бер яңалыгы булып шәхси көндәлекләрне әдәби әйләнешкә кертеп, үзара мәгънәви бәйләнгән өзекләрне авторның шәхси уйланулары белән үремтәдә бирү тора. Сугыш көндәлекләреннән алынган юллар төп шигъри текст белән бәйләнеп, һәр бүлекнең мәгънәви юнәлешен ачыклый. Поэма чикләрендә төрле стиль һәм жанрларның берлеге, интертекстуальлек алымы иҗтимагый, әдәби, фәлсәфи катламнарны барлыкка китерә.

Иҗтимагый уйланулар сугыш чоры вакыйгаларын – фронт, Журовкага бару күренешләрен яңарта һәм эпик башлангычны тәшкил итә. Бу өлештә китерелгән Бакчасарай шәһәрен саткан әтәч турындагы хикәят метафора булып, илгә тугрылык, сату-сатылу мәсьәләсен калкыта. Ватан сугышы вакыйгаларын җанландыру аша фаҗигалелек пафосы тудырыла, аерым образ, әдәби детальләр, хәтта төсләр дә шул максатка хезмәт итә. Мәсәлән, кара төс сугыш фаҗигасенә, үлемнең ямьсезлегенә һәм якынлыгына, язмышның котылгысызлыгына ишарә ясый. Шулай да поэмада сугыш вакыйгаларын тасвирлау беренчел урында тормый, ә Мөҗәйнең эчке дөньясын, рухи кичерешләрен, әхлакый үсеш юлын чагылдыру үзәккә алына.

Шагыйрь, аның халык тормышындагы урыны, вазифасы кебек мәсьәләләр әдәби катламның төп эчтәлеген тәшкил итә. Шагыйрьлек бурычы үз халкың азатлыгы өчен көрәштә дип, милли көрәшче идеалы саналган Тукай бизмәне белән үлчәнә. Кол Гали, Шиһап Мәрҗани, Каюм Насыйри кебек шәхесләрнең әсәр тукымасына кертелүе ике катлам, хәтта капма-каршы мәгънә үткәрә. Тарихи шәхесләрнең рәсемнәре дә калмау, бер яктан, эчке фаҗигане күрсәтсә, икенче яктан, рәсемсез дә үз эшләре белән халык хәтерендә мәңгеләшүләрен раслый.

Поэмада үлем һәм үлемсезлек, вакыт агышы, тән һәм җан сафлыгы турындагы уйланулар фәлсәфи катлам хасил итә. Әсәрнең идеясе дә шунда табыла: кеше – язмыш, үлем – үлемсезлек каршылыклары яшәүнең мәгънәсе, зурлыгы турындагы фикергә алып килә. Гомер агышын шагыйрь руладага – җырның тиз башкарыла торган өлешенә тиңли; гомер – бик тиз үтә торган язмыш бүләге, аны һәркем максатчан, мәгънәле үткәрергә, миссиясен үтәргә тиеш дигән фикергә китерә. Х. Мөҗәйнең кыска гомере Ватан азатлыгы өчен көрәш белән аклана. Җан сафлыгы да шуңа бәйләп аңлатыла.

Яшәү-үлем каршылыгы, үлемнең үлемсезлеккә әйләнү концепциясе фәлсәфәне сугыш чоры поэзиясендәгечә хәл итә: ил азатлыгы өчен көрәш, ил өчен үлү – мәңгелек яшәешнең, ягъни үлемсезлекнең башлангыч ноктасы, үлгәннән соң яшәүгә юл алу буларак шәрехләнә. Лирик геройның вакытсыз өзелгән кыска гомерен ил гомеренә кушарга теләве үлемсезлеккә омтылуы булып аңлашыла: «Минем үлемем – минем Ватаным, минем сыйныфым үлүе түгел ич. Шулай булгач, без: «Безгә үлем юк!» – дибез». Поэманың идеясе дә яшәү мәгънәсе, аның бөеклеге, зурлыгы илгә, Ватанга, үз халкыңа хезмәт итүдә, рухи азатлыкка омтылуда дигән фикер аша үткәрелә: *Утка каршы фидаичә / Януыңны ил көтә. / Йөрәккәйне күңел кошы / «Үлем юк» дип җилкетә, / «Үлем юк» дип җилкетә!* [26, б. 132].

М. Мирза да «Кабатланмас мәңге дигәннәре» поэмасында сугыш вакыйгаларын җентекләп сурәтләүне максат итмичә, алар тәэсирендә туган кичерешләр сызыгын алгы планга чыгара. Һәр сугышның мәңге кабатланмас дип тәмамланып та, даими яңарып торуы әрнү тойгысын иң соңгы чиккәчә үстерә. Г. Тукайдагы «кисмәк өстендә иттифакый

кунган каракош» образына ишарәләгән Каракош-козгын образы, бер яктан, сәяси барышны символлаштырса, икенче яктан, меңләгән кешеләрне үлемгә этәргән сугыш эчтәлегән хасил итә. Ил азатлыгы хакына гомерләрен биргән егетләрнең җаны, аларның тиңсез хәсрәт кичергән аналары каршында Ватан җаваплы дигән фикер әсәрдә төп идея булып яңгырый: *...Ана күз яшендә диңгез тозы – / Йөзен чытмый йоталса Ватан, – / Кабатланмас мәңге, – дигәннәре, / Чынга ашар, бәлки, берзаман* [27, б. 314].

М. Мирзаның бер гасырлык тарихны үз эченә алган «Кысыр Гариф» поэма-кыйссасы бу яктан аеруча көчле яңгырый. Асылда, ул тормыш-яшәешнең үзәге, таҗы булган кешенең сугыш газаплары, рухи фаҗигаләр аша кичеп тә, кешелекле булып калырга омтылуы хакында сөйли. Әсәрнең башында ук «Сугышларны дөнья байлыкларын кабат бүлешү, таланган-яуланган байлыкның хуҗаларын аклау-саклау өчен махсус китереп чыгаралар дип бәяләүчеләр хаклымы әллә» [28, б. 295] соравы куела. Гариф образы аша М. Мирза шул чорның күп язмышларын бер ноктага туплый. Әсәр татар шигъриятенә сугыш фаҗигасен буыннар фаҗигасе итеп таныган, аны фаҗигале үткән итеп бәяләүче, җимерелгән язмышлар өчен әрнүче лирик геройны «кайтара». Шул елларда җимерелгән язмышлар ил киләчәгенә бәйле күзаллана: илнең бәхете дә, хәсрәте дә аерым кешеләр бәхетенә яки кайгысына бәйле дигән фикер ассызыклана.

Ренат Харисның «Бәйрәм калдырырга» (2020), «Үлемсез полк» (2021), «Җырлый беләсеңме» (2021), Эльмира Шәрифуллинаның «Сугыш кырларыннан мин кайтсам?!» һ.б. шигырьләр сугыш мотивының соңгы еллар татар шигъриятендә дә актуальлеген югалтмавын хәбәр итеп мәйданга чыга. Олы Гамь һәм Хәтер мотивы үтәли кисеп барган әлеге әсәрләр Бөек Ватан сугышы вакыйгаларын, заман мөнбәреннән торып, буыннар фаҗигасе төсендә ача. Мисал өчен, Р. Харисның «Үлемсез полк» (2021) шигырендә сугыш буыннар хәтерендә фаҗига булып саклануча күренеш буларак ачыла, лирик геройның хәсрәте дә шуңа бәйле сурәтләнә. «Бәйрәм калдырырга» (2020) шигыре исә ата-бабаларның батырлыгына соклану хисен үзәккә ала, сугыш батырлыгы буыннар хәтерендә саклана торган иң күркәм хатирә дигән фикер шигырьне үтәли кисеп бара: *Әти яулап алган Бөек Җиңү / бәйрәм булып яши йөрәктә. / Ә кешене бәйрәм чын кешечә / яшәү һөнәренә өйрәтә!* [29, б. 3]. Аваздаш фикер Э. Шәрифуллинаның «Җиңү байрагы» (2022), «Днепрны кичү» (2020) шигырьләрендә дә урын ала. Миллионлаган кеше гомере, меңләгән тол хатыннар, ятим балалар язмышы бәрабәренә килгән җиңү ил халкы тарихындагы иң изге, буыннар хәтерендә сакланырга тиешле бәйрәм буларак бәяләнә: *Аямады кара еллар, / Аямады беркемне. / Шөкер, Аллаһ бүләк итте / Бәйрәм килер бу көнне* [30, б. 103]; *Тарихында Бөек Ватан сугышының / Батырлыкта тиңдәше юк ноктасы бу. / Геройлары, орденлысы күп булса да / Елъязманың тәмугка тиң кыйссасы бу!* [30, б. 102].

А. Хәлимнең «Көчле кеше» (2016) нәсерендә дә шул чорны кичергән лирик герой язмышы (Бөек Ватан сугышы башланып, әтисез калу, ачлык фаҗигаләре, илнең 1950 еллардагы ач-ялангач көн күрүе) ил тарихын бәяләү булып гомумиләшә. Шуңа бәйле автор фәлсәфи сораулар куя: кешенең яшәү асылы, яшәү мәгънәсе нидән гыйбарәт? Шушы сорауга җавап төсендә сугышка бәйләп, автор биш хакыйкатьне аерып чыгара: гаилә һәм туганлык җепләре; туган тел һәм әдәбият; безне әйләндереп алган табигать; хезмәт һәм мәхәббәт. Болар сугыш чоры газапларын кичергән автор тарафыннан яшәүнең мәгънәсен, кеше көчен билгеләгән төп сыйфатлар итеп күтәрелә.

## Төп нәтиҗәләр

Бөек Ватан сугышы чоры шигъриятендә поэтик әсәрләр төп игътибарны фронттагы хәлләргә бәйле солдат кичерешләрен сурәтләүгә юнәлтә. Үзләре фронт кырларында булган шагыйрьләр батырлыкка, җиңүгә дан җырлый, совет солдаты, батырлык төшенчәсе идеаллаштырыла һәм поэтик әсәрләр романтик рух, патриотик хисләр белән сугарыла.

Бөек Ватан сугышының җиңү белән тәмамлануы, җәмгыятьтәге горурлык белән өретелгән шатлыклы халәт 1950 елларда сугыш мотивының яктыртылышына да тәэсир ясый. Бер яктан, шагыйрьләр сугыш мотивын колачлы һәм масштаблы сурәтләүгә алына. Мондый әсәрләрдә батырлык темасы, героик-романтик пафос көчле булып, лирик герой иле, аның җиңүе, үзенең шул җиңүгә өлеш кертә алуы белән горурланучы булып чыгыш ясый. Икенче яктан поэзиядә сугышны үзгә яктан, кискен тәнкыйди яссылыкта бәяләү пәйда була. Мондый шигырьләрдә сугыш фаҗигале үткән

буларак бәяләнә башлый, халык авыз иҗатыннан ук танылa торган берәмлекләрне актив куллану сугыш мотивының милли аңланылышына китерә.

XX гасырның икенче яртысыннан сугыш мотивына корылган әсәрләрдәге үзгәрешләр поэтик әсәрләрнең тирән психологизм белән сугарылуына, сугыш вакыйгаларына тәнкыйди карашка бәйле оешып китә. 1950 елларда С. Хәким һәм Ә. Фәйзи иҗатында башланып киткән бу тенденция 1960-80 елларда татар поэзиясенә хас гомумсыйфат булып формалашып җитә. Шигъри әсәрләрдә сугыш вакыйгаларын гомумкешелек фәлсәфәсе яссылыгында бәяләгән лирик герой алга чыга. Үз чиратында мондый текстлар сугыш мотивын сурәтләү юлында лирик психологизмның, фәлсәфилекнең тирәнәюенә китерә. Әлеге сыйфатлар, XX-XXI гасыр чигендәге беркадәр сүлпәнлектән соң, соңгы елларда З. Мансуров, М. Мирза, Р. Харис, Э. Шәрифуллина һ.б. шагыйрьләр тарафыннан кабат тергезелеп, үстерелеп китә.

**Әдәбият**


1. Целкова Л.Н. Мотив // Литературная энциклопедия терминов и понятий. гл. ред. и сост. А.Н. Николюкин. М.: НПК «Интелвак», 2001. 594 с.
2. Кожевникова В.М. Литературный энциклопедический словарь / В.М. Кожевникова, П.А.Николаева. М.: Советская энциклопедия, 1987. 230 с.
3. Заһидуллина Д.Ф. Бөек Ватан сугышы – татар прозасы күзгесендә (татар әдәбиятында сугышны тасвирлауның үзгәреше) // Гасырлар авазы – Эхо веков. 2020. № 2. 51–60 б.
4. Йосыпова Н.М. XX гасырның икенче яртысы татар шигърияте: традицияләр һәм яңачалык. Казан: «Школа» редакция нәшрият үзәге, 2021. 296 б.
5. Йосыпова Н.М., Гайнуллина Г.Р. Татар әдәбияты тарихы: 1940-50 еллар татар әдәбияты: югары уку йортлары студентлары өчен дәреслек. Казан: «Мәгариф – Вакыт» нәшр., 2024. 160 б.
6. Гайнуллина Г.Р. Татарская проза военных лет (1941–1945 гг.) // Научный Татарстан. 2010. № 3. С. 6-16.
7. Габидуллина Ф.И. Хәзерге әдәбиятта сугыш темасы (Ф.Сафин иҗаты мисалында) // Актуальные проблемы современной татарской филологии: сборник статей II Всероссийской научно-практической конференции (11 декабря 2015 г.) / отв. ред. И.Ф.Зарипова. Уфа: РИЦ БашГУ, 2015. С. 249-250.
8. Макарова В. Ф., Каюмова Г. Ф. Отражение темы национального самосознания в творчестве Ш.Ракипова периода Великой Отечественной войны // Материалы III Форума гуманитарных наук «Великая степь» Международная Тюркская академия. Астана, 2018. С.126–131.
9. Хабутдинов А.Ю., Хабутдинова М.М. Военные дневники татарских писателей: путь к читателю сквозь рамки цензуры // Филология и культура. Philology and Culture. 2025. № 2. С. 204–211.
10. Насихова Л.Р. Жанрово-тематические и стилистические особенности татарской фронтовой публицистики в годы Великой Отечественной войны (на примере дневников и очерков). Казань, 2023. 605 с.
11. Насихова Л.Р. Публицистика Хайрутдина Музая в годы Великой Отечественной войны // Вестник Волжского университета имени В.Н. Татищева. 2022. Т. 2. С. 217–223.
12. Терминология современного зарубежного литературоведения. (Страны Западной Европы и США) / отв. ред.: Ильин И.П., Цурганова Е.А. М.: ИНИОН, 1992. 218 с.
13. Борухов Б. Введение в мотивирующую поэтику // Филологическая герменевтика и общая стилистика. Тверь: Изд-во Тверского ун-та, 1992. С. 5–28.
14. Кәрим Ф. Сайланма әсәрләр: шигырьләр, поэмалар, баллада. Казан: Татар.кит.нәшр., 2015. 326 б.
15. Татар әдәбияты тарихы: сигез томда. Т. 5: 1917-1956 еллар. Казан: Татар.кит.нәшр., 2024. 575 б.
16. Фәйзи Ә. Күтәрелә кояш. Казан: Таткнигоиздат, 1954. 526 б.
17. Кәрим Ф. Кыр казы. Казан, 2004. 143 б.
18. Хәким С. Сайланма әсәрләр: ике томда. Т.1. Казан: Татар.кит.нәшр., 1986. 366 б.
19. Туфан Х. Әсәрләр: 5 томда. 1: Шигырьләр һәм поэмалар (1925-1955). Казан: Татар.кит.нәшр., 2007. 479 б.
20. Заһидуллина Д. Көлдә чәчәк аткан гөлләр // Гөлләр үсә көлләрдә. Казан: Мәгариф, 2006. 410–413 б.
21. Галиуллин Т.Н., Йосыпова Н.М. Басынкы елларның дәртле шигърияте // Татар шигърияте: 1960-80 еллар. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 4-15.
22. Лейдерман Н.Л. Современная художественная проза о Великой Отечественной войне. Свердловск, 1974. 144 с.
23. Юзеев И.Г. Мәхәббәт китабы: шигырьләр, җырлар, поэмалар. Казан: Татар.кит.нәшр., 1982. 352 б.
24. Юзеев И.Г. Мәңге ян, күңел!. Казан: Татар.кит.нәшр., 2012. 478 б.
25. Вагапова Л.Н. Поэтика драматургии Ильдара Юзеева. Уфа: Гилем, 2013. 195 с.
26. Мансуров З. Яшәү үзәне. Казан: Татар.кит.нәшр., 1998. 319 б.
27. Мирза М. Сайланма әсәрләр: биш томда. Т.1. Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. 334 б.
28. Мирза М. Сайланма әсәрләр: биш томда. Т.3. Казан: Мәгариф – Вакыт нәшр., 2018. 357 б.

29. Харис Р. Мин – мильон яшьлек кеше! // Казан утлары. 2021. №5. 3–9 б.

30. Шәрифуллина Э. Сугыш кырларыннан мин кайтсам?.. // Казан утлары. 2022. №6. 102–104 б.

# ВОЕННЫЕ МОТИВЫ В ЛИРИКЕ (НА ПРИМЕРЕ ПРОИЗВЕДЕНИЙ, ПОСВЯЩЕННЫХ ВЕЛИКОЙ ОТЕЧЕСТВЕННОЙ ВОЙНЕ)

**Нурфия Марсовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
faikovich@mail.ru.

В статье рассматривается формирование и развитие военных мотивов в татарской поэзии XX в. в контексте современного литературоведения. Материалом для изучения послужили поэтические произведения, посвященные Великой Отечественной войне. Хронологические рамки исследования охватывают период с 1944 по 2025 г. Доказано, что военные мотивы в татарской поэзии зародились в начале XX в., получили новый импульс в своем развитии в годы революции, Гражданской войны, окончательно оформились в годы Великой Отечественной войны. В ходе исследования выявлена трансформация военных мотивов во второй половине XX – первой трети XXI в.

**Ключевые слова:** татарская поэзия, Великая Отечественная война, военные мотивы, трансформация, лирический герой

**Для цитирования**: Юсупова Н. М. Военные мотивы в лирике (на примере произведений, посвященных Великой Отечественной войне) // Tatarica. 2025. № 2 (25). С. 46–65. https://doi.org/10.26907/2311-2042-2025-25-2-46-65